**ҖИР ЙӨЗЕНДӘ ТЫНЫЧЛЫК, ДУСЛЫК, МӘРХӘМӘТЛЕЛЕК, ГАДЕЛЛЕК БУЛСЫН!**

# ХЫЯЛ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ РАЙОНЫ
“ЧАЛМАНАРАТ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРУ МӘКТӘБЕ” УКУЧЫЛАРЫНЫҢ ГАЗЕТАСЫ



## Яңа уку елы белән!

**Гыйлемлелек –**
***инсаннарны мәңге яшәтә торган “тереклек суы” ул. Ансыз һөнәр дә, бәхет тә юк.***
**У.Имәни**

***Укытучы,, мәктәп... Гомер узган саен бу сүзләрне гел искә төшерәбез. Шушы сүзләрне ишеткән саен, балачакка, мәктәп елларына кире әйләнеп кайткан кебек булабыз. Нәкъ җырдагыча, хәтерлим мин әле бүгенгедәй...***

**ДӨНЬЯНЫҢ ТӨРЛЕ ИЛЛӘРЕНДӘ УКУ ЕЛЫ КАЙЧАН ҺӘМ НИЧЕК БАШЛАНА?**

**1 нче сентябрь**
**Рәсәйдә, БДБ һәм Европа илләренең күбесендә**
Белем бәйрәменең атрибутлары бар - тантаналы линейка, мәктәп формасы, укытучыга чәчәкләр.

**3 нче март**
**Көньяк Корея**
Уку июль уртасына кадәр дәвам итә. 2 айлык каникулдан соң – февральгә кадәр II яртыеллык дәвам итә.
I класска 8 яшьтә керәләр.

**Гыйнвар башында яки ноябрьдә**
**Сингапур**
Уку елы 9 ай дәвам итә. Ел тәмамлангач, укучылар сессия тапшыра.

**Август ахыры – сентябрь башы**
**Исландия**
Башлангыч мәктәп 1-7 классларны үз эченә ала һәм бер генә укытучы укыта.
0 дән 10 кадәр билге куялар

## Иҗат җимешебез

## Халык сынамышлары

*Көз көннәре килеп җитте,*
*Хушлашабыз җәй белән.*
*Бөтен җиргә яфраклардан*
*Алтын келәм җәелгән.*

Б...
да –килешләр, ә икенчесендә сораулар яшәгән. Күп еллар үткән, елганың суы кибеп беткән. Килеш белән сорау арасында киртә калмаган. Беркөнне бер килеш үзләренә сораулар сайлап алу кирәклеге турында белдергән. Калган килешләр аның фикере белән килешкәннәр. Бик нык уйлашканнан соң, әлеге килешне баш итеп куйганнар. Аңа ияргәнен иялек дип атаганнар. Икәүләп алга юнәлгәннәр дә, бер килешне сайлап, юнәлеш дигәннәр, шуннан бер чокырга төшеп киткәннәр, ә андагысын төшем дип атап, бергәләп моннан чыкканнар, юлда очраганын чыгыш дигәннәр, вакытны чамалап, бер иптәшне дә тапканнар һәм аның янында яшәп калганнар, шул рәвешле урын-вакыт килеше дә барлыкка килгән.

Сораулар белән парлашып, яшәүләрен дәвам итәләр икән.

А.Хәбирова. V класс укучысы

...ы,
Сентябрь җылы һәм коры булган саен, кыш соңрак килә.

Сентябрь салкын булса, кышын кар тизрәк эри, яз тизрәк килә.

## Спорт - сәламәтлек нигезе



Актанышта узган “Милләтләр кроссы – 2017” дә катнашып, мәктәбебез директоры Гөлнара Рафаэль кызы Әхмәтованы II урын алуы белән котлыйбыз! "Киләчәктә дә уңышлар юлдаш булсын иде" дигән теләктә калабыз.

# Юбилеегыз котлы булсын!



**Энҗе апа!**
**Сезгә корычтай ныклы сәламәтлек, кояштай озын гомер, ак бәхетләр, шатлык, уңышлар телибез.**



«Хыял» Чалманарат төп гомуми белем бирү укучыларының фәнни-популяр, әдәби-нәфис айлык басмасы
Шеф-мөхәррир: Диана Акбулатова Җаваплы сәркатип: Миләүшә Фазлыева Фотохәбәрче: Сәйдәш Шакиров
Безнең адрес: 423752, Чалманарат авылы, Мәктәп ур., 7 нче йорт. E-mail: Schal.Akt@edu.tatar.ru, chalm.akt@yandex.ru Тираж: 15 данә Кул куелды: 08.00; 30.09.2017
Мәктәп компьютерында басылды. Бәясе ирекле. Мәкаләдәге фикерләр өчен мөхәррият җавап тотмый.